| | |
|---|---|
| **СОВЕТ БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

14.10.2022 г. Багай ав. № 11

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Башлыгының һәм муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм вазыйфаи окладларын арттыру турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы органнары әгъзаларының, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрель 6 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә каралганча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре биләгән вазыйфалары нигезендә алар тарафыннан билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә ай саен акчалата түләү күләмнәрен һәм вазыйфаи окладларның күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Әлеге карар аның рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://bagaev-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
авыл җирлеге Багай Башлыгы Р.Ф.Кузнецова